КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1722

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 21 февраль, 169 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 21 февраль, 169 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 июль, 775 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

өченче абзацка «һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә яңадан бүленгән җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә (алга таба - яңадан бүленгән вәкаләтләр)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «һәм яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

4 пунктка «һәм яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктта:

дүртенче абзацка «һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә яңадан бүленгән җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә (алга таба - яңадан бүленгән вәкаләтләр)» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацка «һәм яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, яңадан бүленгән вәкаләтләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктта:

икенче абзацка «һәм яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«279 номерлы карар белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләрне, документларны, материалларны бирү кагыйдәләре нигезендә, яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә түләү алмыйча яки түләүгә файдаланучыларның рәсми сораулары буенча Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материалларны бирүне;

яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә, җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материаллар бирү реестрын алып баруны.»;

2.5 пунктта:

дүртенче абзацка «дәүләт әһәмиятендәге» сүзләреннән соң «һәм яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацка «дәүләт әһәмиятендәге» сүзләреннән соң «һәм яңадан бүленгән вәкаләтләр чикләрендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

2.7 пунктта:

икенче абзацка «җирле әһәмияттәге» сүзләреннән соң «, яңадан бүленгән вәкаләтләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацка «җирле әһәмияттәге» сүзләреннән соң «, яңадан бүленгән вәкаләтләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацка «җирле әһәмияттәге» сүзләреннән соң «, яңадан бүленгән вәкаләтләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

4.2 пунктта «җирле әһәмияттәге,» сүзләрен «яңадан бүленгән вәкаләтләр өлешендә, аларны үзгәртү мөмкинлеге белән җирле әһәмияттәге» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктта «җирле әһәмияттәге,» сүзләрен «яңадан бүленгән вәкаләтләр өлешендә, аларны үзгәртү мөмкинлеге белән җирле әһәмияттәге» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген

мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 21 февраль, 169 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә кушымтаның 10.9 пунктыннан тыш (әлеге карар редакциясендә), әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин